**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕКАБАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул.Южная, дом 1, село. Малые Кабаны
422623, Телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ КАБАН ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кәньяк урамы,1 нчы йорт,
Кече Кабан авылы,
422623 Телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

**2024елның 2 декабре** **11 номер**

# КАРАР

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Олы Кабан авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Олы Кабан авыл җирлеге салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» 2021 елның 19 апрелендәге 10 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1743 статьясы, «Россия Федерациясе субъектлары һәм муниципаль берәмлекләр салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 15 июнендәге 1081 номерлы карары белән, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Олы Кабан авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Олы Кабан авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 19 апрелендәге 10 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Олы Кабан авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибе» нә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 12 пунктның 3 абзацына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Бирелгән ташламаларны түләүчеләр тарафыннан таләп ителгәнлекне бәяләүне уздыру максатларында, Башкарма комитет тарафыннан әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән чагыштырманың минималь күрсәткече билгеләнергә мөмкин, бу очракта ташлама кирәк дип танылачак».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Олы Кабан авыл җирлеге территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам

Татарстан  Республикасы
Лаеш  муниципаль  районы  Олы Кабан
авыл  җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе                    И.Г. Шәрәфиев